# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Күк-Тәкә торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**24 октябрь 2022 ел** **№2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Күк-Тәкә торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2023 елда 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларныц тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаилә әгъзасы булган гаиләләрдән тыш, Тымытык авыл җирлеге Күк-Тәкә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан бер тапкыр түләтүне 200 сумга киметеп, үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

1) Күк-Тәкә авылында Өске зиратны коймалау өчен материаллар сатып алу (материал сатып алу һәм хезмәтләр өчен килешү буенча түләү).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Тымытык авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Тымытык авыл җирлеге башлыгы Э.Х. Гыйләҗева